ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары эшчәнлегендә катнашуы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары эшчәнлегендә актив катнашырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советларын төзегәндә аларның составына, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне һәм бурычларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын да кертүне тәкъдим итәргә.

3. Муниципаль районнар һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне һәм бурычларны исәпкә алып, тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары составына кертү турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның попечительлек һәм күзәтчелек советлары эшчәнлегендә катнашуы турында»

2014 елның 19 ноябрендәге 155-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 11 (VII өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Т.П. Ларионовага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәмmәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 17 декабре
№ 201-VI ДС